# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛКИ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

# КАРАРЫ

**2018 елның 02 апреле** **10№**

## Әлки муниципаль районы Башлыгының 2017 елның 18 декабрендәге Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм вазыйфаи затларның шәхси кабул итү тәртибен раслау турында" 75 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы вазыйфаи затларының гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхсән кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертергә:

1. 5 бүлекнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3) 2006 елның 02 маендагы "Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 59-ФЗ номерлы 11 статьясында күрсәтелгән очраклардан тыш, мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча язмача җавап алырга,

2. 7 бүлекнең 7.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"7.3. Дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән мөрәҗәгать әлеге Федераль законда билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш. Мөрәҗәгатьтә граждан үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы - булган очракта), җавап җибәрелергә тиешле, мөрәҗәгатьне яңадан адреслау турында хәбәрнамә җибәрелергә тешле электрон почта адресын мәҗбүри рәвештә күрсәтә. Граждан мондый мөрәҗәгатькә кирәкле документларны һәм материалларны электрон рәвештә кушып бирергә хокуклы."

3. 7 бүлекне түбәндәге эчтәлектәге 7.7.1 пункты белән тулыландырырга:

"7.7.1. Язма мөрәҗәгать тексты тәкъдимнең, гаризаның яисә шикаятьнең асылын билгеләргә мөмкинлек бирмәгән очракта, мөрәҗәгатькә җавап бирелми һәм ул үз компетенцияләре нигезендә дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка карауга юлланмый, бу хакта мөрәҗәгатьне теркәгән көннән алып җиде көн эчендә мөрәҗәгатьне җибәргән гражданга хәбәр ителә."

4. 7 бүлекне түбәндәге эчтәлектәге 7.7.2 пункты белән тулыландырырга:

"7.7.2. Дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка җавабы "Интернет"мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге дәүләт органы яисә җирле үзидарә органы мәгълүматларының рәсми сайтында урнаштырылган язмача мөрәҗәгать кергән очракта, 2006 елның 2 маендагы

"Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 59-ФЗ номерлы карарның 4 өлеш нигезендә

5.8 бүлекне түбәндәге эчтәлектәге 8.3 пункты белән тулыландырырга:

"8.3. Мөрәҗәгатькә җавап электрон документ рәвешендә дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон почта адресы буенча һәм дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка язма рәвештә мөрәҗәгать иткәндә күрсәтелгән почта адресы буенча җибәрелә. Моннан тыш, тәкъдим, гариза яисә шикаять булган, билгесез затлар даирәсе мәнфәгатьләренә кагыла торган дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка кергән мөрәҗәгатькә, аерым алганда, билгесез затлар даирәсенә карата чыгарылган суд карарына шикаять бирелә торган мөрәҗәгатькә җавап, шул исәптән суд карарын шикаять итү тәртибен аңлатуга бәйле рәвештә, әлеге Федераль законның 6 статьясындагы 2 өлеше таләпләре үтәлгән килеш дәүләт органының яисә җирле үзидарә органының рәсми сайтында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылырга мөмкин."

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstaN.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Әлки муниципаль районы Советының гомуми бүлеге башлыгы М.А. Советниковка йөкләргә.

Әлки муниципаль районы Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Р. А. Билалов

Тихомиров Д.М.
8 (84346) 20051